# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 6** **10.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге составына керүче Сөякәй торак пунктына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Сөякәй торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Сөякәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә. Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм анда катнашучылар, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Әфганстандагы хәрби хәрәкәтләрдә һәм башка локаль конфликтларда катнашучылар, шулай ук көндезге формада укучы студентлар өчен 350 (өч йөз илле ) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

1. Сөякәй авылы янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

2. Сөякәй авыл халкының ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

3.Рәсми мәдәни-массакүләм чараларны оештыру;

4. Сөякәй авылы җирлеген төзекләндерүне оештыру;

5. Сөякәй авылында ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

6.Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, Сөякәй авылы суларын чыгаруны оештыру;

7. Сөякәй авылы җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге;

8. Сөякәй авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру

9. Сөякәй авылының территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслату;

10. Сөякәй авылы территориясендә яшәүче күзәтүчесез хайваннарны тоту чараларын оештыру".

3.Әлеге кабарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда , Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Сөякәй авылы, Тукай урамында урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Октябрь авыл җирлеге башлыгы И.М.Ханнанов